**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 30 март № 199

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 елда агро-сәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2017 ел, 10 февраль, 77 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2017 елда агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2017 ел, 10 февраль, 77 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган 2017 елда авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә үсемлекчелек өлкәсендә, орлык бәрәңге һәм ачык грунт яшелчәләрен җитештерүне үстерү өлкәсендә файдалану юнәлешләре мөстәкыйль билгеләнә торган ярдәм күрсәтүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибендә:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Субсидия субсидия бирү турында килешү төзү планлаштырыла торган айга кадәр айның беренче көненә субсидия алучы түбәндәге таләпләргә туры килә торган шартларда бирелә:

законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм Татарстан Республикасы территориясендә җитештерү эшчәнлеген гамәлгә ашыра;

үзгәртеп төзү, бетерү яки банкротлык стадиясендә түгел һәм хуҗалык эшчәнлеге алып баруга чикләүләре юк;

чит ил юридик затлары, шулай ук устав (җыелма) капиталларында теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән салым салуның ташламалы салым режимы һәм (яки) финанс операцияләре үткәргәндә мондый юридик затларга мөнәсәбәттә мәгълүматны ачу яки бирү күздә тотылмаган дәүләт яки территория (офшор зоналар) булган чит ил юридик затлары өлеше гомумән алганда 50 проценттан артып киткән россия юридик затлары түгел;

әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга бүтән норматив

хокукый актлар, муниципаль хокукый актлар нигезендә Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан акча алмаган;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән бүтән хокукый актлар нигезендә бирелгән, Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына кайтару буенча вакыты чыккан бурычы һәм Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджеты каршында бүтән вакыты чыккан бурычы юк.

Субсидия алучы алга таба алынган акчаларны әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән чараларга, шулай ук салымнар, җыемнар һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетына бүтән мәҗбүри түләүләргә тотуын раслауны тәэмин итә.»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Әлеге Тәртипнең 5 һәм 6 пунктларында күрсәтелгән субсидияләрне алу өчен субсидия алучылар Министрлыкның Татарстан Республикасы муниципаль районнарындагы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренә (алга таба – Идарәләр) Министрлык раслаган форма буенча, үзләренең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, форма буенча субсидия бирү турында гариза тапшыра, анда шул исәптән түбәндәге мәгълүмат та була:

субсидия алучы үзгәртеп төзү, бетерү яки банкротлык стадиясендә түгел һәм хуҗалык эшчәнлеге алып баруга чикләүләре юк;

субсидия алучы чит ил юридик затлары, шулай ук устав (җыелма) капиталларында теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән салым салуның ташламалы салым режимы һәм (яки) финанс операцияләре үткәргәндә мондый юридик затларга мөнәсәбәттә мәгълүматны ачу яки бирү күздә тотылмаган дәүләт яки территория (офшор зоналар) булган чит ил юридик затлары өлеше гомумән алганда 50 проценттан артып киткән россия юридик затлары түгел;

субсидия алучы әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга бүтән норматив хокукый актлар, муниципаль хокукый актлар нигезендә Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан акча алмаган;

субсидия алучының субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән бүтән хокукый актлар нигезендә бирелгән, Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына кайтару буенча вакыты чыккан бурычы һәм Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджеты каршында бүтән вакыты чыккан бурычы юк;

субсидия алучы законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм Татарстан Республикасы территориясендә җитештерү эшчәнлеген гамәлгә ашыра.»;

11 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучылар белән Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән типик форма нигезендә һәм Министрлык раслаган вакытларда субсидия бирү турында килешү төзиләр. Субсидия бирү турында килешүдә субсидия бирүнең нәтиҗәлелеге күрсәткечләре, субсидия бирүнең нәтиҗәлелегенә ирешү һәм әлеге Тәртипнең 4 пункты нигезендә алынган акчаны куллануны раслау турында хисап тапшыру тәртибе, рәвеше һәм вакытлары күздә тотыла. Субсидия бирүнең нәтиҗәлелеге күрсәткечләре исемлеген Министрлык раслый.»;

12 пунктның икенче абзацында «субсидия алучыларның исәп-хисап счетларына» сүзләрен «субсидия алучыларның Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счетларына» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2017 елда авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә сөтле терлекчелектә продуктивлыкны арттыруга юнәлдерелгән, Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибендә:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Субсидия субсидия бирү турында килешү төзү планлаштырыла торган айга кадәр айның беренче көненә субсидия алучы түбәндәге таләпләргә туры килә торган шартларда бирелә:

законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм Татарстан Республикасы территориясендә җитештерү эшчәнлеген гамәлгә ашыра;

үзгәртеп төзү, бетерү яки банкротлык стадиясендә түгел һәм хуҗалык эшчәнлеге алып баруга чикләүләре юк;

чит ил юридик затлары, шулай ук устав (җыелма) капиталларында теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән салым салуның ташламалы салым режимы һәм (яки) финанс операцияләре үткәргәндә мондый юридик затларга мөнәсәбәттә мәгълүматны ачу яки бирү күздә тотылмаган дәүләт яки территория (офшор зоналар) булган чит ил юридик затлары өлеше гомумән алганда 50 проценттан артып киткән россия юридик затлары түгел;

әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга бүтән норматив хокукый актлар, муниципаль хокукый актлар нигезендә Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан акча алмаган;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән бүтән хокукый актлар нигезендә бирелгән, Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына кайтару буенча вакыты чыккан бурычы һәм Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджеты каршында бүтән вакыты чыккан бурычы юк.

Субсидия алучы алга таба алынган акчаларны субсидия алучының җитештерү эшчәнлегенең төп төрләренә тотылуын, шулай ук салымнар, җыемнар һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетына бүтән мәҗбүри түләүләргә тотуын раслауны тәэмин итә.»;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән субсидияләрне алу өчен субсидия алучылар Идарәгә түбәндәге документларны тапшыра:

Министрлык раслаган форма буенча, үзләренең түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, форма буенча субсидия бирү турында гариза тапшыра, анда шул исәптән түбәндәге мәгълүмат та була:

субсидия алучы үзгәртеп төзү, бетерү яки банкротлык стадиясендә түгел һәм хуҗалык эшчәнлеге алып баруга чикләүләре юк;

субсидия алучы чит ил юридик затлары, шулай ук устав (җыелма) капиталларында теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән салым салуның

ташламалы салым режимы һәм (яки) финанс операцияләре үткәргәндә мондый юридик затларга мөнәсәбәттә мәгълүматны ачу яки бирү күздә тотылмаган дәүләт яки территория (офшор зоналар) булган чит ил юридик затлары өлеше гомумән алганда 50 проценттан артып киткән россия юридик затлары түгел;

субсидия алучы әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга бүтән норматив хокукый актлар, муниципаль хокукый актлар нигезендә Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетыннан акча алмаган;

субсидия алучының субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән бүтән хокукый актлар нигезендә бирелгән, Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына кайтару буенча вакыты чыккан бурычы һәм Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджеты каршында бүтән вакыты чыккан бурычы юк;

субсидия алучы законнарда билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм Татарстан Республикасы территориясендә җитештерү эшчәнлеген гамәлгә ашыра;

2017 елның гыйнвар – февралендә сөт җитештерү күләмнәре, сатылган һәм (яки) үзе җитештерүгә алынган сөт күләмнәре турында мәгълүматлар;

субсидия алучы тарафыннан расланган, 2017 елның гыйнвар – февралендә субсидия алучы сыер сөтен яки кәҗә сөтен сату һәм (яки) үзе җитештерүгә алу фактын раслый торган товар йөкләмәләре күчермәләре;

хисап финанс елына һәм хисап финанс елына кадәрге елга сыерлар һәм (яки) кәҗәләрнең баш саны турында рәсми статистик хисапларны формалаштыра торган мәгълүмат (сөт җитештерү буенча хуҗалык эшчәнлекләрен хисап финанс елында башлаган авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрдән тыш);

субсидия бирүне сорап мөрәҗәгать иткән айның 1нче көненә сыерлар һәм (яки) кәҗәләрнең баш саны турында рәсми статистик хисапларны формалаштыра торган мәгълүмат;

хисап финанс елына һәм хисап финанс елына кадәрге елга сыерларның сөт продуктивлыгы турында рәсми статистик хисапларны формалаштыра торган мәгълүмат (сөт җитештерү буенча хуҗалык эшчәнлекләрен хисап финанс елында башлаган авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләрдән тыш);

сөтне үзләре эшкәртүне гамәлгә ашыручы субсидия алучылар хуҗалык эчендә кулланыла торган товар йөкнамәсе күчермәсен (сөтне күчереп йөртүгә), үзе эшкәртүгә алынган товар сөтенең пландагы үзбәясен күрсәтеп, бухгалтериядән белешмә һәм сөт продукциясенә яраклылык сертификатын тапшыра;

Министрлык раслаган форма буенча тиешле субсидияләр турында белешмә-исәп.

Тапшырылган документлар күчермәләре субсидия алучы тарафыннан таныклана.»;

7 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән типик форма буенча һәм Министрлык раслаган вакытларда субсидия алучылар белән субсидия бирү турында килешү төзи. Субсидия бирү турында килешүдә әлеге Тәртипнең 4 пункты нигезендә субсидия бирүнең нәтиҗәлелеге күрсәткечләре, субсидия бирүнең нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү һәм алынган акчаны куллануны раслау

турында хисап бирү тәртибе, формасы һәм вакытлары күздә тотыла. Субсидия бирүнең нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен Министрлык раслый.»;

8 пунктның икенче абзацында «субсидия алучыларның исәп-хисап счетларына» сүзләрен «субсидия алучыларның Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счетларына» сүзләренә алмаштырырга;

2017 елда озак вакытлы, уртача вакытлы һәм кыска вакытлы кредитлар буенча процентларны түләүгә чыгымнарның бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль бюджет белән бергә финанслана торган субсидияләр бирү тәртибендә:

4 пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучының (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнан тыш) Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына салымнар, җыемнар һәм бүтән мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә түләү вакыты җиткән бурычы юк.»;

11 пунктта:

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«субсидия алучының (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнан тыш) Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына салымнар, җыемнар һәм бүтән мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә түләү вакыты җиткән бурычы юк;»;

унберенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидия алучылар үз инициативалары белән заемга алучының Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджетына салымнар, җыемнар һәм бүтән мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә түләү вакыты җиткән бурычы юклыгы хакында салым органыннан белешмә тапшырырга хокуклы. Әлеге документ субсидия алучы тарафыннан (шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнан тыш) үз инициативасы белән тапшырылмаган очракта Министрлык аны ведомствоара мәгълүмати багланышлар тәртибендә соратып ала.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — И.Ш.Халиков